**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Тенеш җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 24 сентябре** **№** 83-рс

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы**
**Тенеш җирлеге территориясендә**
**гражданнарның үзара салым акчаларын**
**кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле**
**референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

12.06.2002 елның 67 номерлы "Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокуклары гарантиясе һәм референдумда катнашу хокуклары турында" Федераль законның 15 статьясы , 2003 елның 6 октябрендәге « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "гы 131 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында " 23 номерлы Татарстан Республикасы законының 18 статьясы, "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш җирлеге"
муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьялары, 2018 елның 18 сентябрендә кабул ителгән 10 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» гы Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш җирлеге Башкарма комитеты карары, 2018 елның 24 сентябрендәге 82-рс номерлы « Җирле референдум үткәрү инициативасы турында»Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш җирлеге Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

- 1. Җирле референдумга чыгарылган сорауны расларга:
  «2019 елда» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы " муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ гражданнан 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, көндезге формада белем алучы студентлар), түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме:

*** җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**
**- Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчылар обелискын төзекләндерү.»**

1. Әлеге карарны ТР., Кама Тамагы районы,Тенеш поселогы, Ленин ур., 8 йорт адресы буенча урнашкан халыкка җиткерү мәгълүмат стендларына куярга,
шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Тенеш җирлеге Башлыгы,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Тенеш җирлеге Советы рәисе И.Т. Гиниятов